2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлеге Бикәсаз авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

22 ноябрь 2024 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең Бикәсаз авылы гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең Бикәсаз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләр) төзекләндерү.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Бикәсаз авылы, Мәктәп урамы, 1А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Кәшер авыл җирлеге башлыгы Л.М. Гыйниятуллина